РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.03.2019 Олы Кайбыч авылы № 18

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районында**
**Кибердружина төзү турында**

Интернет челтәрендә экстремистик, милләтчел, җинаятьчел контентлы язмалар чыгуга каршы һәм аларны кисәтү максатыннан үткәрелә торган чараларны башкару, халыкта киберкуркынычсызлык турында мәгълүмат булдыру өчен, 2006нчы елның 6нчы мартында чыккан 35-ФЗномерлы «Терроризмга каршылык күрсәтү турында» Федераль законы, Россия Федерациясе Президентының 2006 нчы елның 15нче февралендә чыккан 116 номерлы «Терроризмга каршылык күрсәтү чаралары турында» Әмере, Татарстан Республикасы Президентының 2006 нчы елның 4нче апрелендә чыккан УП-128 номерлы «Татарстан Республикасында антитеррористик комиссия эшен оештыру мәсьәләләре турында» Әмере нигезендә

**КАРАР КЫЛАМ:**

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында Кибердружина төзергә.

2. Түбәндә саналганнарны Кушымта итеп бирелә торганнарны расларга:
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль район Кибердружинасы турында нигезләмә (кушымта №1);
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кибердружинасының составы (кушымта №2).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендә рәсми сайтында һәм информацион - телекоммуникацион Интернет челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнашкан “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**А.И.Рәхмәтуллин**

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башлыгының 2019елның 15нче мартында чыккан 18нче номерлы карарына Кушымта № 1

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районында Кибердружина турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

**1. Төп нигезләмәләр.**

1.1. Әлеге «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында Кибердружина турында» Нигезләмәсе (алга таба – Нигезләмә) Интернет челтәрендә җинаятьчел һәм шәхес сәламәтлегенә, үсешенә зыян китерергә мөмкин булган мәгълүмат таралуга каршылык күрсәтү максатыннан эшләнде.

1.2. Әлеге Нигезләмә түбәндәгеләргә нигезләнә:

- Россия Федерациясе Конституциясе;
- 2010нчы елның 29нчы декабрендә чыккан 436-ФЗ номерлы «Балаларны аларның саулыгына һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан саклау турында» Федераль законы;
- 2003нче елның 6нчы октябрендә чыккан 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законы;
- 2014нче елның 5нче маенда чыккан 97-ФЗ номерлы «Мәгълүмат, мәгълүматый технологияләр һәм мәгълүмат саклау турында» Федераль законына һәм Россия Федерациясенең информацион–телекоммуникацион челтәр аша мәгълүмат алмашу мәсьәләләре турындагы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” федераль законы.

1.4. Әлеге Нигезләмә Кибердружина эшчәнлегенең максатын, бурычларын һәм тәртибен билгели.

1.5. 18 яшьтән олырак Интернет челтәрендә җинаятьчел һәм тискәре мәгълүмат таратуга каршылык күрсәтүнең мөһимлеген аңлаучы һәм ирекле рәвештә бу эшкә булышырга әзер булган физик затлар Кибердружина әгъзалары булып тора ала.

1.6. Кибердружина әгъзалары үз эшчәнлекләрен законлылык, үз ирке белән башкару, шәхси һәм социаль җаваплылык принципларыннан чыгып тормышка ашыра.

1.7. Россия Федерациясе Милли Антитеррористик комитеты карарлары, Татарстан Республикасы Антитеррористик комитеты карарлары, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Антитеррористик комитеты карарлары Кибердружина өчен мәҗбүри.

## 2. Кибердружина максатлары һәм бурычлары.

2.1. Кибердружина максатлары:

- Интернет челтәрендә җинаятьчел мәгълүмат, шулай ук шәхес сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерергә мөмкин булган мәгълүмат таралуга каршылык күрсәтү;
- Интернет челтәрендә хокук мөнәсәбәтләрен көйләүче канунчылыкка иҗтимагый контроль;
- хокук саклау органнарына Интернет челтәрендә яңа төр хокук бозуларны ачыклау, шулай ук моның белән көрәшү эшендә ярдәм күрсәтү.

2.2. Кибердружина бурычлары:

- наркотиклар пропагандасы, суицидка өндәү һәм башка төрле куркыныч контентлы сайтларны ачыклау максатында интернет мониторингы;
- Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы халкын Интернет челтәрендә җинаятьчел мәгълүматка тап булган очракта башкарылырга тиешле эшләр белән таныштыру;
- Дружина әгъзаларын махсус әзерләү, укыту;
- Дәүләт структураларына Россия Федерациясендә Интернет челтәрендә таратылу тыелган мәгълүмат белән көрәш эшенә булышу;
- Дружинага яңа әгъзалар җәлеп итү максатыннан мәгълүматый-аңлату һәм агитацион-пропаганда эше алып бару.

## 3. Кибердружинаның эш тәртибе.

3.1. Төркем үз эшен иректе рәвештә план буенча тормышка ашыра. Кибердружина планы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Антитеррористик комитеты утырышында раслана.

3.2. Җинаятьчел мәгълүмат таратучы интернет – ресурслар эзләү.

3.3. Ачыкланган мәгълүматны хокук саклау органнарына тапшыру.

3.4. Деструктив контент белән көрәш методлары турындагы мәгълүматый – пропаганда материалларны Интернет челтәрендә урнаштыру.

3.5. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Антитеррористик комиссиясен үз эшчәнлегең белән таныштыру.

3.6. Төркем карарлары тәкъдим характерында.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башлыгының 2019елның 15нче мартында чыккан 18нче номерлы карарына Кушымта № 2

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районы Кибердружинасы**
**СОСТАВЫ**

| № п/п | Ф.И.О. | Эш урыны |
|---|---|---|
| | **Җитәкчесе** | |
| 1 | Лотфуллина Зөһрә Фирнат кызы | ТР Кайбыч МР Башкарма комитеты ЯСФКһС бүлеге начальнигы |
| | **Әгъзалары:** | |
| 2 | Михайлов Юрий Валтер улы | «Форпост»Үзәге директоры |
| 3 | Федотов Игорь Николай улы | ТР Кайбыч МР Башкарма комитеты гомуми бүлеге мөдире |
| 4 | Смелов Максим Виктор улы | «Олы Кайбыч УГББМ» МБГББУ нең информатика укытучысы |
| 5 | Демьянова Елена Сергеевна | «Иске Тәрбит УГББМ» МБГББУ нең информатика укытучысы |
| 6 | Козлов Сергей Владислав улы | «Хуҗа Хәсән УГББМ» МБГББУ нең информатика укытучысы |
| 7 | Шихов Игорь Валерий улы | «А.Е.Тутаев исемендәге Федоровск» УГББМ» МБГББУ нең информатика укытучысы |